**Республика Татарстан**
**Исполнительный комитет**
**Большенуркеевского сельского**
**поселения Сармановского**
**муниципального района**

**Татарстан Республикасы**
**Сарман муниципаль районының**
**Зур Нөркәй авыл җирлеге**
**башкарма комитеты**

---

ПОСТАНОВЛЕНИЕ
07 октябрь 2020 ел

КАРАР
№ 7

«Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең акчалата керемнәре турында» нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

«Үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлекләр башлыкларының, муниципаль берәмлекләр башлыклары урынбасарларының, депутатларның, җирле үзидарәнең сайланулы органнары әгъзаларының, муниципаль берәмлекләрнең контроль-хисап органнары рәисләренең һәм муниципаль хезмәткәрләрнең вазыйфаи окладларының айлык акчалата түләү күләмнәрен арттыру турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 06 августындагы 658 номерлы карары нигезендә Зур Нөркәй авыл җирлеге башкарма комитеты карар бирә:

2018 елның 23 апрелендәге 2 номерлы карары белән расланган «Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Зур Нөркәй авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең акчалата керемнәре турында» Нигезләмәгәгә түбәндәге үзгәреш кертергә:

1) 1 нче кушымтаның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2. Муниципаль хезмәткәрләр муниципаль хезмәтнең муниципаль вазыйфасына бәйле рәвештә авыл җирлегендә муниципаль хезмәт вазыйфаларының кече төркеме билгеченең вазыйфаи окладының 1,03 тапкыр күләмендә һәм 11 498 сум күләмендә билгеләнә ».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» (PRAVO.TATARSTAN.RU ) һәм «Интернет»мәгълүмат – телекоммуникация челтәрендә «Сарман муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең рәсми сайтында урнаштырырга .

3. Әлеге карар 2020 елның 1 октябреннән гамәлгә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Зур Нөркәй авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе Р.М.Гайсин